
Абдулла Алиш



# Сертотмас үрдәк

Нашрият бу китапны чыгаруда матди ярдәм
курсәткәне өчен "Татнефтепродукт"
Акционерлык жәмгыятенен Генераль директоры
Сабиров Рөстәм Наил улына рәхмәт белдерә.





Борын заманда башы бүрекле, аягы төкле бер үрдәк булган. Ул үзе сайрый белмәсә дә, күргән бер кошына, хайванына, ерткычына озак-озак итеп яңа хәбәрләр сөйләргә бик ярата икән. Тегеләр аның сүзләрен тыңлый-тыңлый арып бетәләр, я бөтенләй тыңламый ташлап китәләр икән. "Ишеттеңме бер яңа хәбәр? Сиңа гына сер итеп сөйлим",—дип башлап китә торган булган ул сүзен.




Бердәнбер көнне йорт хуҗасы үзенең этен ияртеп, корыч балтасын биленә кыстырган да урманга киткән. Йортындагы һәрбер кош-кортына: "Өйдә юклыгымны берәүгә дә белдермәс булыгыз!"—дигән.





"Нигә белдермәскә кушты икән?"—дип, үрдәк йөдәп чыккан, ләкин ни өчен икәнен һич төшенә алмаган.

Кош-кортлар хуҗаларыннан башка бер кич кунганнар, берни булмаган. "Икенче көнне дә кайтмас бу",— дип, алар хуҗаны чакырып кайтырга берәрсен җибәрергә булганнар.




"Син очасың да, син йөзәсең дә, син йөгерәсең дә, син бар!"—дигәннәр алар үрдәккә. "Ләкин берүк нишләп йөрүеңне берәүгә дә белгертәсе булма!"—дигәннәр. Үрдәк үпкәләгән: "Ярар, сезнең хакыгыз өчен генә барсам барырмын инде",—дигән.





Иртә торгач та үрдәк, уйлап-нитеп тормаган, тамагын туйдырган да юлга чыккан. Башта ул канатларын кагып очкан, оча-оча бер елгага барып төшкән.





Ишкәкләре—тәпиләре үзендә булганга аптырамаган, йөзеп тә киткән. Елга буйлап озак йөзгәч, корыга чыгып, тәпи-тәпи дә йөгергән...





Бара-бара куе бер урманга барып җиткән. Төрле тәмле җиләкләр, симез бөҗәкләр ашый-ашый, урманга да кереп киткән.

Үрдәк күбәләк куып йөргәндә, аның каршысына бер керпе килеп чыккан һәм аңа сүз дә кушкан:


—Кая барасың болай?—дигән.





Үрдәккә инде шул гына кирәк тә икән. Юл буе берәү дә очрамаганга, берәү белән дә җәелеп сөйләшергә туры килмәгәнгә, аның бик эче пошкан булган, иптәшләренең әйткәннәрен дә онытkan, сүз артыннан сүзне тезәргә тотынган:






—Урманда утын кисүче хуҗабызны эзлим. Җитмәсә, этебез дә аңа ияреп киткән иде. Хәзер йорт-җирне саклаучы берәү дә юк. Аларны чакырып кайтырга иптәшләрем мине җибәрделәр,—дигән.

—Синең өең еракмы соң?—дигән керпе.— Анда симез тычканнар, усал еланнар юкмы?—дип сораган. Аның үз хәле хәл, бик нык ашыйсы килә икән.

— Менә шушы сукмак безнең өйгә туп-туры алып бара, бер кешегә дә әйтмә, кара!— дигән үрдәк. Өйләрендә еланнарның бөтенләй юклыгын, тычканнарга көн бирмәүче мәченең шуклыгын да сөйләп биргән.

— Мин инде андый усалларның берсе дә түгел, синең серләреңне белсәм дә, каян килүеңне күрсәм дә, сиңа зарарлы эш эшләмәм. Шулай да син саграк бул. Очраган берәүгә серләреңне сөйләмә. Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр, җимерелмәслек нык булыр,— дигән.





Керпенең бу акыллы киңәшенә үрдәк һич колак салмаган, ашыга-ашыга урман эченәрәк атлаган.

Бара-бара үрдәккә озын колаклы бер куян очраган һәм ул да аңардан сораган:

—Әй, бүрекле үрдәк, күзгә төсле матур, кыр төсле зур күл булганда, ни эшләп урманда буталып йөрисең?





—Хуҗабыз белән этебез урманга утын кисәргә киткәннәр иде, өебез ялгыз калды,— дигән үрдәк, керпегә сөйләгәнне моңа да сөйләп биргән.— Куян эченнән генә: "Алай булгач, хуҗаның алмагачларын кимерергә барырга бик җайлы вакыт икән",— дигән. Үрдәктән өйләренең кайдалыгын сорашкан, теге юләр моңа да серен ачкан.



—Хуҗаңны күргәнем юк,— дигән дә куян куаклык эченә кереп югалган.

Үрдәк тагын алга киткән. Бара-бара бер аланлыкка барып җиткән. Анда бер зур соры аю мышный-мышный йоклап ята икән. Үрдәк аны да уяткан. Керпе белән куянга сөйләгән сүзне аңа да сөйләп биргән. Сүз ахырында аюдан сораган:

—Эт иярткән, кулына балта тоткан кешене күрмәдеңме?



Аю:

—Күрмәдем,— дип җавап биргән. Үрдәкнең кайгысын уртаклашкандай булып кыланган:

—Урман эченәрәк керсәң, һичшиксез, табарсың,— дип, юл өйрәтеп җибәргән. Ә үзе эченнән генә: "Хуҗаның умартасын ватып, бал ашап кайтырга бик җайлы вакыт икән",— дип, ашыгаашыга китеп тә барган.





Үрдәк һаман хуҗаны эзләвен дәвам иттергән. Анын саен урманның эченәрәк керә барган. Бара торгач, аның каршына бүре килеп чыккан һәм аңа сүз кушкан:

—Әй, бүрекле баш, шушындый куе урманда япа-ялгызың гына курыкмыйча батырланып ничек йөрисең?— дигән. Теге дә үзенең ник йөрүен сөйләп биргән.



Хуҗаның өйдә юклыгын, этнең дә аның белән бергә ияреп китүен бүрегә дә әйткән. Усал бүре тешләрен шыкылдаткан, үз-үзенә: "Боларның сарыкларын барып ашап кайтырга бик җайлы чак икән",— дигән, ә үрдәккә: "Андый кешене күргәнем юк!"—дигән дә үзе куаклар арасына кереп югалган.

728770
ЦЕНТРАЛИЗОВАННАЯ
СИСТЕМА
г. НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ




Үрдәк һаман туктамаган. Хуҗасын эзләүне һаман дәвам иткән. Күргән бер коштан, төрле ерткычтан, хәтта нәни бөҗәкләрдән дә бу турыда сорашып бара икән.



Бара-бара аның каршысына көлтәдәй койрыклы бер төлке килеп чыккан. Теге дә ахмак бит, моңа да сүз кушкан:

—Багалмакай, матур апакай, минем хуҗамны күрмәдеңме?— дигән.—Янында эте, кулында балтасы бар иде,—дип өстәгән. Хуҗасыз һәм этсез өйдәге хайваннарның тынычсызлануларын, алардан башка куркуларын да сөйләп биргән.




—Чибәрләрнең чибәре, гәүһәрләрнең гәүһәре, күрдем мин аны!— дигән төлке.— Янында кәкре койрыклы эте дә, биләндә корыч балтасы да бар иде,— дип өстәгән. Үрдәкне үзе белән ияртеп киткән. Алар бик озак барганнар һәм куак белән капланган елга буена килеп туктаганнар.



Шунда төлкенең оясы буенда балалары уйнап йөри икән.

Алар:

—Әни, безгә азык алып кайттыңмы?— дип, аның тирә-юнен сырып алганнар, ә ул, авызын ерган килеш, үрдәккә күрсәткән...



—Менә, бәбкәләрем, сезгә тәмле үрдәк ите,— дигән һәм шул минут үрдәкне буып, балаларына бүлеп тә биргән. "Үрдәк ите бигрәк тәмле була икән!"—дип, алар, авызларын ялый-ялый, аны ашап та ташлаганнар, ләкин туймаганнар, аналарыннан тагын сораганнар.

—Хәзер, бәбкәләрем, авылга барам, берьюлы берничә үрдәк алып кайтам,— дигән төлке. Балаларын калдырып, авылга киткән.





Бер Сертотмас үрдәк аркасында бу хуҗалык тәмам туздырылган булыр иде, ләкин хуҗа уяу кеше булган, дошманнарына каршы һәр җирдә киртә куйган. Куян рәшәткә арасыннан үтә алмаган, кире борылган. Аю бәрәңге базына төшкән. Бүрегә дә сарыклар эләкмәгән, хуҗалык абзарына ул бөтенләй керә алмаган.



Төлке хәйләкәр булса да, сыза алмый калган, үрдәк ите ашыйм дигәндә генә, капкынга эләккән, ә хуҗа кайткач инде, аның кирәген биргән..."Тагын берничәне тоткач, толып тектерермен",—дигән һәм тиресен киптерергә амбарга элгән.

Хайваннар эшнең нидәлеген хуҗага сөйләп биргәннәр, Сертотмасны шундый зур эшкә кушуларына алар да бик нык үкенгәннәр.



Издание для детей дошкольного и
младшего школьного возраста

АБДУЛЛА АЛИШ

БОЛТЛИВАЯ УТКА
Сказка.
(на татарском языке)

ИБ 139

Производствога тапшырылды 30.10.98. Басарга кул куелды 18.11.98.
Кәгазь форматы 60Х90 $^{1}/_{8}$. 100 гр. офсет кәгазе №1. Басма табагы 3.
Тиражы 5 000 данә. Заказ Я-506. Лиц. № 0232 21.04.98

"Татар китабы" нәшрияты. 420012. Казан, Мөштәри ур., 14.
Издательство "Татарская книга". 420012. г.Казань, ул. Муштари, 14.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты типографиясе.
420066. Казан, Декабристлар ур.,2.

